ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

07.12.2022　　　　　　Иннополис шәһәре　　　　　　99

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләре җыентыгын раслау турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләренең тышкы төренә һәм техник характеристикаларына карата бердәм таләпләрне раслау максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Иннополис шәһәре Башкарма комитетына тапшыру турында» 2015 елның 8 маендагы килешү нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Иннополис шәһәре Башкарма комитетына тапшыру турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 2015 елның 7 маеннан 58-570 номерлы карары белән

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләре җыелмасын Кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләре җыентыгында каралмаган реклама конструкцияләрен урнаштыру «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә рөхсәт ителми.

3. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыруга рөхсәт ителә торган реклама конструкцияләре җыентыгын раслау турында» 2022 елның 31 октябреннән 51 карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Хуззятов